**Тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыру турында**

**КИЛЕШҮ.**

**№ 3**

*(килешүнең теркәү номеры)*

Зеленодольск шәһәре «14» декабрь 2025 ел

РФ Бюджет кодексын гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 декабрендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Уставы буенча эш итүче Афанасьев Михаил Павлович рәисе исеменнән ТР Зеленодольск муниципаль районы Советы (алга таба – муниципаль районның вәкиллекле органы) , Зеленодольск муниципаль районы Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмә буенча эш итүче Кадыйрова Светлана Викторовна рәисе исеменнән «Зеленодольск муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» МУ һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы буенча эш итүче Бишнә авыл җирлеге Советы рәисе исеменнән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советы, алга таба «Яклар» дип аталучылар, 2025 елның 13 декабрендәге 38 номерлы муниципаль район вәкиллекле органы карарын һәм 2025 елның 08 декабрендәге елның 15 номерлы җирлек вәкиллекле органы карарын үтәү йөзеннән түбәндәгеләр турында әлеге Килешү төзеделәр.

**1. Килешү предметы**

1.1. Әлеге Килешүнең предметы булып Зеленодольск муниципаль районы Контроль-хисап палатасына (алга таба – район контроль-хисап органы) җирлек контроль-хисап органының (алга таба – җирлек контроль-хисап органы) тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыру тора.

1.2.Контроль-хисап палатасына федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, җирлек уставында һәм җирлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән җирлекнең контроль-хисап органы вәкаләтләре тапшырыла.

1.3.Җирлек бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү һәм җирлек бюджеты проектына экспертиза ел саен районның контроль-хисап органы эш планына кертелә.

1.4. Башка контроль һәм эксперт-аналитик чаралар районның контроль-хисап органы эш планын формалаштыру өчен билгеләнгән срокларда җирлекнең җирле үзидарә органнары тәкъдимнәре нигезендә районның контроль-хисап органы эш планына кертелә.

Әлеге Килешү нигезендә контроль һәм эксперт-аналитик чаралар районның контроль-хисап органының эш планына аерым бүлек (бүлекчә) белән кертелә.

**2. Килешүнең гамәлдә булу срогы**

2.1. Килешү өч елга төзелгән һәм 2026 елның 01 гыйнварыннан 2030 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

2.2.Килешүнең гамәлдә булуын туктату турында якларның берәрсе язмача мөрәҗәгать итмәгәндә, Килешүнең гамәлдә булу срогы чыкканга кадәр, Килешү биш елга озайтылган дип санала.

**3. Якларның хокуклары һәм бурычлары**

3.1. Муниципаль районның вәкиллекле органы:

3.1.1) муниципаль хокукый актларда әлеге Килешүдә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча районның контроль-хисап органы вәкаләтләрен билгели;

3.1.2) әлеге Килешүдә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кирәклеген исәпкә алып, район контроль-хисап органының штат санын билгели;

3.1.3) районның контроль-хисап органыннан әлеге Килешүдә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру һәм үткәрелгән контроль һәм эксперт-аналитик чаралар нәтиҗәләре турында мәгълүмат ала.

3.2. Районның контроль-исәп органы:

3.2.1) үз эшенең планнарына кертә:

ел саен - җирлек бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү һәм җирлек бюджеты проектына экспертиза ясауны;

законнарга каршы килми торган срокларда – тышкы дәүләт финанс контроле өлкәсендә федераль законнар, Конституция(Устав) һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне.

3.2.2) чараны үткәрү инициаторы белән килештереп билгеләнгән срокларда (әгәр сроклар законнарда билгеләнмәгән булса) үз эше планында каралган чараларны уздыра;

3.2.3) җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерүгә әзерләү өчен тиешле ел дәвамында җирлек бюджеты үтәлешен һәм җирлек бюджеты акчаларыннан файдалану буенча контрольне гамәлгә ашыру хокукына ия;

3.2.4) уздырыла торган чараларның формаларын, максатларын, бурычларын һәм үтәүчеләрен, аларны үткәрү ысулларын, тикшерелә торган органнарны һәм оешмаларны үз регламенты һәм тышкы муниципаль финанс контроле стандартлары нигезендә һәм чараны үткәрү инициаторы тәкъдимнәрен исәпкә алып билгели;

3.2.5) башка органнар һәм оешмалар белән берлектә, аларның белгечләрен һәм бәйсез экспертларын җәлеп итеп, контроль һәм эксперт-аналитик чаралар уздырырга хокуклы;

3.2.6) җирлекнең вәкиллекле органына уздырылган чаралар нәтиҗәләре буенча хисаплар һәм бәяләмәләр җибәрә, күрсәтелгән материалларны җирлекнең башка җирле үзидарә органнарына җибәрергә хокуклы;

3.2.7) «Интернет» челтәрендәге үзенең рәсми сайтында үткәрелгән чаралар турында мәгълүмат урнаштыра;

3.2.8) җирлек администрациясенең күрсәтмәләрен һәм тапшыруларын, башка тикшерелә торган органнарга һәм оешмаларга җибәрә, ачыкланган хокук бозуларны бетерү һәм булдырмау буенча законнарда каралган башка чараларны күрә;

3.2.9) бюджет процессын, җирлек милкендәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү системасын камилләштерү мөмкинлекләре ачыкланганда, җирлекнең җирле үзидарә органнарына тиешле тәкъдимнәр җибәрергә хокуклы;

3.2.10) әлеге Килешүдә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен каршылыклар барлыкка килгән очракта, аларны бетерү буенча тәкъдимнәр белән җирлекнең вәкиллекле органына мөрәҗәгать итә ала.

3.3. Җирлекнең вәкиллекле органы:

3.3.1) уздырыла торган чараларның сроклары, максатлары, бурычлары һәм башкаручылары буенча тәкъдимнәрне, аларны үткәрү ысулларын, тикшерелә торган органнар һәм оешмаларны үз эченә алган контроль һәм эксперт-аналитик чаралар уздыру турындагы тәкъдимнәрне районның контроль-хисап органына җибәрә;

3.3.2) контроль-хисап органының контроль һәм эксперт-аналитик чаралар уздыру нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрен һәм тәкъдимнәрен карый;

3.3.3) массакүләм мәгълүмат чараларында уздырылган чаралар турында мәгълүматны бастырып чыгарырга, районның контроль-хисап органы хисапларын һәм бәяләмәләрен җибәрергә хокуклы;

3.3.4) әлеге Килешүдә каралган вәкаләтләрне башкару өчен каршылыкларны бетерү уңаеннан районның контроль-хисап органы мөрәҗәгатьләрен карый, аларны бетерү өчен кирәкле муниципаль хокукый актларны кабул итә.

3.3.5)Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр еллык бюджетара трансфертлар күләменең дүрттән бер өлеше күләмендә, 4 квартал өчен күрсәтелгән кварталның соңгы аеның 20 числосына кадәр еллык бюджетара трансфертларның дүрттән бер өлеше күләмендә бюджетара трансфертларны район бюджетына тапшыруны тәэмин итә,

3.4. Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган башка чараларны кабул итү хокукына ия.

**4. Бюджетара трансфертларның еллык күләмен билгеләү**

4.1. Әлеге Килешүне предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру ел саен муниципаль берәмлек бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бюджет законнарына туры китереп бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән башкарыла

4.2. Яклар ел саен тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләмен әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган Кушымтада каралганча билгели.

**5. Килешүне үтәмәгән өчен финанс санкцияләре.**

5.1. Бюджетара трансфертларны күчерү срогы бозылган очракта, бюджетара трансфертларны күчерү буенча йөкләмәне үтәү вакыты узган һәр көн өчен 0,01% күләмендә пенялар исәпләнә.

5.2. Җирлектән алынган һәм әлеге Килешүне гамәлгә ашыру максатларында файдаланылмаган бюджетара трансфертлар, бирелгән бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмау факты суд тәртибендә билгеләнгәннән соң, ике айдан да соңга калмыйча район бюджетыннан җирлек бюджетына кайтарылырга тиеш.

**6. Якларның җаваплылыгы**

6.1. Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Килешү нигезендә әлеге Килешүдә каралган бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен Яклар җавап тоталар.

6.2. Әлеге Килешүдә каралган тапшырылган вәкаләтләрне үтәүне туктатып тору һәм бюджетара трансфертлар күчерү очракларында, шулай ук бурычларны үтәмәү (тиешенчә үтәмәү) муниципаль район администрациясе, җирлек администрациясе яисә башка өченче затларның гамәлләре нәтиҗәсендә җибәрелгән булса, яклар җаваплылыгы барлыкка килми.

**7. Йомгаклау нигезләмәләре**

7.1.Әлеге Килешү барлык Яклар тарафыннан имзаланган көннән үз көченә керә.

7.2. Әлеге Килешүгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы буенча әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган язма рәвештә өстәмә килешү төзү юлы белән кертелергә мөмкин.

7.3.Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы Яклар килешүе буенча я муниципаль районның вәкиллекле органы яисә җирлекнең вәкиллекле органы тарафыннан башка Якларга Килешүне өзү турында хәбәрнамә җибәргән очракта алдан туктатылырга мөмкин.

7.4.Килешү, Яклар килешүендә башкасы каралган очраклардан тыш, үзенең эшчәнлеген туктату турында килешү төзегәнгә (хәбәрнамә юлламасына) кадәр башланган контроль һәм эксперт-аналитик чаралары тәмамланганнан соң,гамәлдә булуын туктата.

7.5. Әлеге Килешүне үтәгәндә барлыкка килгән Яклар тарафыннан җайга салынмаган бәхәсләр һәм каршылыклар гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә тикшерелергә тиеш.

7.6. Әлеге Килешү бер үк юридик көчкә ия өч нөсхәдә Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә төзелде.

Зеленодольск муниципаль районы
Советы
Рәисе
________________М.П. Афанасьев
(Имзалау датасы)

Бишнә авыл
жирлеге Советы рәисе
______________ И.М.Фатхуллин
(Имзалау датасы)

Зеленодольск муниципаль районы
«Контроль-хисап палатасы»МУ
Рәисе
________________С.В. Кадыйрова